**Бишенче Якупов укулары: “Мөселман эпиграфиясендә татар гореф гадәтләрен өйрәнү һәм саклау”**

# РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

*Казан 15.09.2016*

15 сентябрь 2016 нчы елны Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Россия ислам институты һәм Казан федераль университеты белән бергәлектә Бишенче Якупов укулары үткәрелде. Чарада татар галимнәр, күренекле дин әһелләре, журналистлар һәм шәкертләр катнашты. Әлеге фәнни-гамәли конференция 2012 елдан башлап танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов эшчәнлегенә багышлап үткәрелә.

Быелгы конференция рухи мирасыбызны өйрәнү эшчәнлеген дәвам итеп, “Мөселман эпиграфикасында татар гореф-гадәтләрен өйрәнү һәм саклау” темасына багышланган иде. Әлеге тема соңгы вакытта Яңа татар зиратында вандаллык күренеше килеп чыгу сәбәпле җәмәгатьчелектә аерым бер игътибар яулады. Белгәнебезчә, күптән түгел 100дән артык кабергә зыян салынды, бу вакыйга күпләрне тетрәндерде. Тарихи юнәлешләрне торгызу бик әхәмиятле эш булып тора.

Конференциядә катнашучылар шуны расладылар: Татар халкының бик бай булган мөселман эпиграфик традициясен өйрәнергә һәм саклап калырга. Бу эшне тормышка ашырыр өчен түбәндәге пунктлар кирәк дип табылды:

1. Шәһәрләрдә һәм авыл җирлекләрендә татар-мөселман зиратларын тиешле тәртиптә тоту. Аның өчен имам һәм мөхтәсибләр белән төрле җыештыру чаралары оештыру.

2. Бик начар хәлдә булган борынгы зиратларны реставрацияләүдә дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтү.

3. Татар-мөселман эпиграфикасын өйрәнү буенча фәнни совет оештыру (дин әһелләре, галимнәр, җәмәгать эшлекләре һ.б.).

4. Татар-мөселман эпиграфикасына багышланган күп томлы гыйлми хезмәт әзерләргә.

5. Россия күләмендә татар-мөселман эпиграфикасына багышланган фәнни-гамәли конференция оештырырга.

6. Татар-мөселман зиратлары булган Россия төбәкләренә экспидицияләр оештыру.

7. Иң борынгы һәм тарихи каберлекләргә туристик маршрут әзерләү.

8. Татар-мөселман зиратлары өстеннән шефлык итү (карап тору)
9. Зират әдәбе турында листовка-өндәмәләр бастырып тарату.
10. Җәй-көзге экспедицияләргә актив рәвештә мәдрәсә шәкертләрен дә тартырга.
11. Татар-мөселман зиратларында күмелгән шәхесләрнең тормыш юлларын өйрәнергә
12. Татар-мөселман зиратларының тамгалар белән интерактив картасын булдырырга.